**АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш, Проспект Ленина,дом 58.Тел.3-15-99

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт. Тел.3-15-99

**КАРАР**

№ 8 «09» апрель 2020 ел

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең 2020-2036 елларга социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 1 октябрендәге 1050 номерлы карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең 2020-2036 елларга комплекслы социаль инфраструктурасын үстерү программасын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 йорт;. Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Юбилей урамы, 4 нче йорт;Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 56а адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актаныш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш авыл Башкарма комитеты җитәкчесе И.С.Шәмсунов